Хәмидуллина, Р. Г. Гасырга тиң гомер / Р. Г. Хәмидуллина // Мәйдан. – 2024. - № 6. – Б. 127-133.



# ГАСЫРГА тиң ГОМЕР

***Өйдә гел җылылык, елмаю, тыныч кына бер-берсе белән аралашу. Инде гаилә тормышының кырык биш елы артта калса да, бер-берсен күз карашыннан аңлап, мәхәббәт җепләрен саклап яшиләр кебек алар. Мин бүген Сәгыйтовларда кунакта, 95 яшен тутырып килгән Зөфәр абый өчен ихлас сөенеп утырам.***

## Җиһанша бабай оныгы

Зөфәр Ярулла улы Сәгыйтов 1929 елның 12 августында Татарстанның Чаллы (хәзерге Тукай) районы Биклән авылында туган. Себернең алтын приискасына барып эшләп, ике ат йөге җиһаз төяп алып кайткан Җиһанша бабай оныгы ул.

Җиһанша бик эшчән кеше була. Көнне-төнгә ялгап эшли. Эшләп тапкан һәр тиенен җыеп бара. Әчтелтем эчемлекләр, матур бичәләр, комарлы уеннар аны кызыктырмый. Акчаны үз көчен түгеп туплый. Туган авылыннан еракта озакка каласы килми егетнең. Күңеле түренә кереп оялаган туган якларга кайтырга дигән уй аның исеннән бер минутка да чыгып тормый. Ике ат җигеп, нәкъ менә үзе эшләп тапкан акчага ике йөк әйбер төяп, туган авылына кайтып төшә. Бу адымы ул еллар өчен шаклар китәрлек гамәл була. Җиһанша бабай алып кайткан җиһазлар - бу яклар өчен соклангыч әйберләр. Әнә бүгенге көндә дә алар фатирында немец физгармуны белән француз сәгате саклана. «Нәрсә ул физгармун?» дигән сорауга, кечкенә орган, диеп аңлатты Зөфәр абый. Шул арада хатыны Людмила ханым органның тавышын ишеттереп уйнап та алды. «Соклангыч матур тавышлы», - дигән җөмләмә җавап итеп:

- Зөфәр бит аны һәрдаим карап, чистартып тора, шуңа ул үз тавышын югалтмый, - диеп әйтеп куйды Людмила ханым. Ә Зөфәр абый:

- Бабайны мин белмим, ә хәте-

ремдә алып кайткан әйберләр арасында бик матур чынаяклар да бар иде кебек. Өебез җыйнак, матур иде. Әбием Гайшәбикә матур киенеп йөрде. Шундый җиңел тунын хәтерлим әле мин аның, йомшак иде үзе. Әбинең аяк киемнәре, күлмәкләре дә авыл хатыннарыныкыннан үзгә булды. Бик белемле иде. Ул туксан өч яшенә кадәр яшәде. Авылга рус телле кеше килсә, әби артыннан киләләр - үз вакытында тылмач ролен дә башкара Гайшәбикә әби.

Ул вакытларда авылларда мәдәният йортлары булмый. Җәй көннәрендә Җиһанша бабайның өй каршы шул рольне үти. Музыканы яраткан, берничә уен коралында уйный белгән бабай кичке якта авыл халкын ял иттерә. Өй тәрәзәсен ачып куеп, читтән алып кайткан граммофонын куша. Яшьләр җыела, җыр, бию, төрледән-төрле уеннар граммофоннан яңгыраган көй астында башкарыла.

Авыл халкы өйгә кереп җиһазларны да карап чыга. Бабай алып кайткан өстәл, урындыкларны, сәке урынына куелган караватны күреп сокланалар. Осталар, өйдәге җиһазларны күреп, үзләре дә шуңа охшатып ясый башлыйлар.

Читтә йөреп, күпне күреп кайткан бабай бик миһербанлы кеше була. Авыл халкына гел ярдәм күрсәтеп яши. Революциядән соң авылда байлар рәтендә йөргән бабайны да Себергә сөрергә телиләр. Ә авыл халкы бердәм булып Җиһанша бабайны яклап кала.

Бабайның гаиләсе зур була: өч малай, ике кыз тәрбияләп үстерә. Балаларын күрше Бәтке авылындагы урыс мәктәбендә укыта.

# Әтисе Ярулла - беренче тракторчы

Җиһанша картның оныгы Зөфәр гаиләдә өченче бала буларак дөньяга килә. Аннан соң бер кыз, бер егет тә алып кайта әле әниләре. Зөфәрнең балачагы эш белән үтә, уйнарга уенчыклар булмау сәбәпле, машина, тракторларны ул агачтан үзе ясый. Техниканың көпшәләре, рульләре дә кул белән тимердән ясала. Әмма уенчык машиналар белән озак уйнарга гына туры килми, Зөфәр уенчык техниканы чыннарына тиз алыштыра.

- Әтием Ярулла Биклән авылына беренче тракторны алып кайткан кеше, - дип дулкынланып сөйли ул.

Харьков трактор заводыннан баржаларда Идел, аннан Чулман елгалары буйлап Чаллы районына тракторлар кайта. Кичкырын тракторлар төягән баржа Чаллыга килеп туктый. Яңа тракторны алырга Ярулланы җибәрәләр. Ул таң атып килгәндә трактор белән Биклән авылына кайтып керә. Трактор тавышына авылда этләр өрә, сыерлар мөгри башлый, халык куркуга төшеп, урамга чыга. Ярулла, тракторыннан төшеп, халыкны тынычландыра:

- Бу мин, - ди, - колхоз кырларын сукалар өчен трактор алып кайттым.

Халык арасыннан бер батыр егет чыгып тракторга суккалап карый. Аннары Ярулладан утыртып каравын сорый. Утырта Ярулла, тагын бер-ике егетне тракторда йөрергә, җир сукаларга өйрәтә. Үзенә алмаш әзерләгән Ярулланы туган авылыннан утыз чакрым ераклыктагы «Кызыл Чапчак» эшчеләр бистәсендәге МТСка инженер-механик итеп. җибәрәләр. Эшчеләр өчен төзелгән йорттан фатир алганнан соң, гаиләсен дә үзе белән алып китә.

Зөфәр биш-алты яшеннән әтисенә ияреп эшкә йөри башлый. Әтисенең эш урынында комбайн, машина, тракторлар күп була. Кыш көннәрендә дә эш җитәрлек. Техниканы язгы кыр эшләре өчен әзерлисе бар. Зөфәр әтисенең уң кулына әйләнә. Башта әтисе эшләгәнне игътибар белән күзәткән егет үзе дә техника серләренә төшенә.

Тормыш үз җаена матур гына барганда, гаиләгә кайгы килә. «Халык дошманы» дип, МТС хезмәткәрләрен - директорны, механикны һәм инженер булып эшләүче Ярулланы да кулга алалар. Тикшерү сигез ай бара. Егетләр бу айларны төрмәдә үткәрәләр. Йомшак күңелле Ярулланың күңеленнән гаиләсе китми. Хатыны биш бала белән бит! Ничек яшәмәк кирәк? Аларны уйлап, ашаудан да, йокыдан да кала яшь ир. Шул борчылулар аны сигез ай дигәндә кабергә тыга. Аның үлеменнән соң гына МТСның эш күрсәткечләре буенча республикада икенче урынны алуы билгеле була. Директор белән механик икесе дә акланып, эш урыннарына әйләнеп кайталар. Ә Ярулла гаиләсенә эшче поселокта инде урын калмый, яшәгән йортларын тиз арада бушатырга кушалар. Барысы бергә алты җан Бикләндә яшәүче әбиләре Гайшәбикә янына кайталар. Җиһанша бабайга боларны күрергә, кичерергә туры килми, ул инде мәрхүм була. Авылда әбиләре күршесендә ике катлы мулла йорты буш тору сәбәпле, гаилә шунда яши башлый. Ике катлы йорт: беренче каты - таштан, икенчесе - агач. Алар беренче катында гомер итәләр. Берен- че-икенче классларны МТСта тәмамлаган Зөфәр Бикләнавылы мәктәбендә өченче-дүртенче классларда белем ала. Әниләренә авыл җирендә ишле гаилә белән яшәү авыр була, күрәсең, аның гаиләсен алып Чаллы шәһәренә күченәсе килә. Ул елларда авылдан читкә китү, моның өчен паспорт юнәтү бик авыр була. Шәһәргә барып эш белешеп кайткан Мәликә бәхетен сынап карарга диеп Авыл советына рөхсәт сорап бара. «Мин тегүче, өйдә эшләячәкмен. Калада эш табып кайттым, алар көтәләр», - ди. Авыл советы җитәкчеләре аңа авылдан китәргә рөхсәт кәгазе бирәләр.

Чаллыга килгәч, әниләре җыелган күпмедер акчасына йорт сатып ала.

- Әнием тырыш кеше иде, - дип искә ала Зөфәр абый. - Гаиләне ашату, укыту өчен аңа күп эшләргә туры килде. Безне әни ул вакытта Чаллыда бердәнбер булган Мулланур Вахитов исемендәге татар мәктәбенә укырга бирде. 1

## «Иптәш Сәгыйтов»

Зөфәр җиденче сыйныфны тәмамланган елны сугыш башлана. Әниләре сугыш өчен гимнастерка, чалбар һәм башка кирәк-яраклар тегә. Биш бала тәрбияләүче ханымга өйдә эшләргә рөхсәт итәләр. Ул бик еш кына өчәр норма үти. Аңа Зөфәр дә ярдәм итә. Бүгенге көндә дә өйнең түрендә ул елларда аларны ачлык-ялангачлыктан алып калган «Зингер» тегү машинасы тора.

- Машина тегәме? - дигән сорауга Людмила ханым:

- Тегә, авыр заманнарда - 90 нчы елларда Зөфәр миңа күлмәк, итәкләр тегеп биргән иде әле, - дип елмаеп, сүзгә кушылып ала.

Әнисе гомерен тегүче булып үткәрә, балаларын хезмәт белән яшәргә өйрәтеп үстерә. Сиксән җиде яшендә үлеп китә.
Ә Зөфәр, бер дә уйламаганда, киномеханик булып китә. 1943 елда Яр Чаллы кинотеатры директоры Иван Агафонов

физика фәненнән бишле билгеләренә генә укучы өч малайны сайлап ала - алар арасында Мулланур Вахитов исемендәге мәктәпнең җиденче сыйныфын тәмамлаган Зөфәр дә була.

- Син нәрсә эшли беләсең соң? - дип ышанмагандай көлемсерәп сорый директор. Зөфәр:

- Бар нәрсәне дә эшли алам, - дип җавап кайтара.

Иван Агафонов егетне төрле яклап тикшереп карый. Кинотеатрда ватылып яткан киноаппаратны төзәтеп карарга куша. Бер ай эчендә эшләп чыксаң, бик рәхмәтле булам, ди. Зөфәр аны ун көндә төзәтә. Аппаратның бер тавышсыз эшләгәнен күргәч, җитәкче, егетнең белеменә, уңганлыгына сокланып: «Булдыргансың, иптәш Сәгыйтов», - ди. һәм шул көннән соң Иван Григорьевич аны хөрмәт итеп «Иптәш Сәгыйтов» дип йөртә башлый.

Киномеханиклыкка айлык курслар үткәч, аны җитәкче итеп куялар. Ул елларда Чаллы районы буйлап, авылдан-авылга барып, кино күрсәтеп йөри алар. Шакирҗанов Мидхәт исемле егет белән бергә Сарманда да кино күрсәтү җайланмасы урнаштыралар. Шунда яшәп, бер еллап кино күрсәтәләр. Авыл халкы кинога төрле вакытта килә. кайвакыт халыкның җыелып бетүен озаклап көтәргә туры килә. Авыл халкы газета алмый, радио да бөтен жирдә эшләми. «Китапханәләр дә мәктәпләрдә генә иде кебек», - дип искә ала Зөфәр абый. Шуңа күрә кинотеатр халыкны агарту эшен дә алып барырга тиеш була. Зөфәр абый стенага плакатлар язып элә. Кайберләре һаман исендә: «Из всех искусств для нас важнейшим является кино» (Ленин), «Наше дело правое, мы победим» (Сталин).

Тамашачылар плакатны укый-укый ятлап бетерә. Клуб халык белән шыгрым тулгач, башта унике минутлык сугыш яңалыклары күрсәтелә. Аннан төп кино башлана. Ул елларда халыкның яратып йөри торган кинолары: «Чапаев», «Радуга», «Два бойңа», «Депутат Балтики», «Парень из нашего города», «Свинарка и пастух», «Истребитель», «Она защищает Родину» һәм башкалар.

## Авылдан авылга - үгез җигеп

Авылдан-авылга йөргәндә кызык һәм кызганыч хәлләргә белән еш юлыгырга туры килә аларга. Еш кына арбага җигәргә атлар җитешми] бу вазифаны үгезләр, сыерлар үти.

- Бервакыт күрше авылга барабыз диеп чыксак, үгезләр урынында өч яшь хатын-кыз җигелгән иде. Алар - алдан, без икәү арттан этеп барабыз, кызлар бер җырны тәмамлыйлар да икенчесен башлыйлар, берсеннән-берсе уздырып, төрледән-төрле мәзәкләр сөйлиләр. Күрше авылга барып җиткәнебезне сизми дә калдык, - дип елмаеп искә ала Зөфәр абый.

Бервакыт исә үгез җигелгән арба белән авылга килеп керәләр - аларны анда этләр өреп каршы ала. «Этләрне күрү белән үгезебез аларны куа башламасынмы, - дип сөйли Зөфәр абый. - Авылның бер тыкрыгы калмады, этләрне күздән югалткач кына үгезне туктата алдык. Соңыннан гына билгеле булды: кайчандыр бу үгезнең аягын эт тешләгән булган икән, шуның үчен алган, күрәсең.

Ә бервакыт үгезләре киреләнә, үгез куып килүче егет нәрсәләр белән генә алдап карамый - мәгънәсе юк. Шуннан егет, үгезнең койрыгын күтәреп, салам кыстырып куя да ут төртеп җибәрә.

Хайван чаба башлый. Авылга бик тиз килеп җитәләр. Тик инде хәзер үгезне туктата алмыйлар. Дилбегәне кинәт тарту белән, чана авып китә. Кино әрҗәләре белән бергә егетләр дә, төрле якка мәтәлеп төшеп, көрткә чумалар. Ә үгез читән өстендә асылынып тора. «Тугарырга кирәк», - диләр кызлар. Тугарылгач, шуны гына көткән үгез читәннән скереп чыгып та китә.

Киноны исә халык күтәп ала, рәхәтләнеп карый. Сугыштан яраланып кайткан ир-атлар кино тәмамланганнан соң да кайтып китәргә ашыкмый әле, сөйләшеп арыганнан соң гына өйләренә таралышалар.

## Кинодан - музыкага

- Сугыштан соң Чаллы каласында ятимнәр өчен балалар йорты ачылды, - дип сөйләвен дәвам итте Зөфәр абый. - Хәзерге вакытта ул йортлар юк инде. Красногвардейская дигән, су кырыйлап урнашкан урам бар иде. Шул урамдагы йортларның берсендә ачылды ул. Безнең күрше апа бу оешмада хисапчы булып эшли иде. Балаларның тормышын күңеллерәк итеп оештыру өчен, җитәкчелек музыка уен коралларында уйный белүче эзли икән.

Кыскасы, күрше апасы Зөфәрнең аккордеонда бик шәп уйнавын җиткерә. Җитәкчегә шул гына кирәк тә. Ул аны киномеханик эшеннән азат итүләрен сорап, горкомга бара. Ул елларда горком сүзе - закон. Шулай итеп аны балалар йортына музыка хезмәткәре итеп күчерәләр. Өйдә генә уйнаган Зөфәр нәрсәдән башларга да белми. Тик балалар дөньясы аны үзенә бик тиз җәлеп итә. Тәрбиячеләр белән бергә, ул балаларны җырларга, биергә өйрәтә.

Бер ел эшләгәннән соң, музыка мәктәбендә беренче класс ачыла.

Шулай тырышып эшләп йөргән чагында аны армия сафларына алалар. Ул Красноярск өлкәсенең Ачинск шәһәренә авиация хезмәтенә эләгә. Дүрт еллык Авиация мәктәбен ике елда тәмамлыйлар солдатлар. Илдә ТУ-4 самолеты әзерләнеп бетә. Аларның частен Украинаның Нежин каласына, аннан - Конотоп, озак та тормый Лебедино шәһәренә күчерәләр. Егет армиядә дә инструменталь ансамбль оештыра. Борт инженеры буларак, самолетларны сынауда катнаша. Дүрт ел вакыт шулай үтә. Офицер дәрәҗәсе алып, армиядә калу мөмкинлеге булса да, аны туган яклары үзенә тарта.

Авиациядә армия хезмәтен үтәп кайткан Зөфәр Чаллы аэродромына эшкә урнаша. Ләкин эшеннән канәгать булмый. Абыйсы Мисбах чакыруы буенча Фирганәгә чыгып китә. Мисбах ул елларда мәктәптә музыка укыта. Энесен дә үзе янына машиноведение укытырга урнаштыра. Аккордеонда яхшы уйнаган Зөфәр моның белән генә чикләнми, мәдәният йортына эшкә урнаша, кичләрен биюләр оештыра. Эшләп тапкан акчасын әнисенә җибәреп тора. Әнисе исә бу акчага сеңелләрен укыта.

Өч еллап чит җирләрдә эшләгәннән соң, егет туган шәһәренә әйләнеп кайта. Үзе тәмамлаган Мулланур Вахитов исемендәге мәктәпкә музыка укытучысы булып урнаша, һәм, сәләтле укучыларны җыеп, өч тавышка җырлаучы хор төзи. Ел ахырында мәктәпләр арасында смотр-конкурслар була. Хорның чыгышын, конкурска җибәргәнче, мәктәп укытучыларына тыңлатып карыйлар. Өч тавышка җырлауны укытучыларның берсе дә аңламый.

- Бу хор белән оятка калмабызмы? - диләр бик күпләр. Шулай да, Зөфәрнең дәлилләрен ишеткәч, каршы килмиләр.

Мулланур Вахитов исемендәге мәктәп хоры сәхнәгә иң соңгы булып күтәрелә. Өч тавышка туган ил турында татар телендә җыр яңгырый. Жюри шакката! Жюри әгъзаларының берсе - скрипкачы егет: «Беренче урын бары тик аларга!» - ди. һәм шуннан соң егерме ел эшләү дәверендә мәктәп хоры беренчелекне башка мәктәпләргә бирми. Шул елларда Зөфәр Сәгыйтов башта Алабуга культура-агарту училищесын, аннан Казан педагогия институтының музыка факультетын тәмамлый. Югары белем егеткә җиңел бирелә, чөнки ул үзлегеннән бик күп методик дәреслекләрне укыган, әзерләнгән була.

## Машинага җан өреп...

Музыкадан тыш, егеткә хезмәт укытучысы вазифасын да тәкъдим итәләр. Ишегалдында буш яткан корылмага җан кертә егет, аны ике өлешкә бүлеп, берсендә слесарь, икенчесендә столяр эшләрен укучыларга өйрәтү өчен кабинетлар булдыра. Укучыларны үзе белгән тимер, агач эшләренә өйрәтә. Алай гына да түгел, шуларга өстәп, аңа мәктәптә машиноведение дәресе дә укытырга туры килә. Дәресне практика белән бәйләп алып бару өчен машина кирәк була. Директор, укытучы Зөфәр соравы буенча, яраксызга чыгарылган бер машинаны мәктәп ишек алдына алып кайтып куя. «Мин бу машинаны җыеп чыгачакмын», - ди Зөфәр. Бу сүзләргә Зөфәрнең үзеннән башка берәү дә ышанмый. Ул машина запчастьләре табуга күп көч куя. Чаллыдагы металлолом җыю урынында эшләүче танышына машина запчастьләре кирәклеген әйткәч, тегесе: «Монда бар нәрсә дә бар, эзләргә генә кирәк», - дип җавап бирә. Чынлап та, бер-ике ай дигәндә, машина көпчәкле була. Аннан мотор, поршеньнәр, свеча һәм башкалар да үз урыннарына кереп урнаша. Зөфәрнең тырышлыгы белән, бер ел дигәндә, машина сафка баса. Мәктәп өчен бу көн бәйрәмгә әйләнә. Директорны утыртып, автоинспекциягә номер алырга баралар. Шул рәвешле Зөфәр сүзендә тора белүен тагын бер кат дәлилли.

1960 елда исә биш кеше утырышлы аэрочана ясап шәһәр халкын шаккатыра. Шактый вакыт ишле гаиләсе белән Бикләнгә үзе ясаган чанада кайтып йөри.

- Электроплуг та ясады бит әле ул, - дип Людмила ханым да әңгәмәгә кушыла. - Аның белән бик күп еллар бакча җирен эшкәрттек.

Бүген яшәгән алты почмаклы өен дә 1963 елда үз куллары, үз проекты белән салып кергән Зөфәр абый.

Минем дә безнең Чаллы үзәк китапханәсендә сәнгать бүлеген бизәгән пианино, әдәбият тарихы музеенда урын алган балалайка, гармуннарны Зөфәр абыйның сизгер куллары төзәткәнен әйтеп үтәсем килә.

## Бер картина турында

Ә хәзер сүзем бер картина турында. Зөфәр абый үзе ясый аны. Картинада сурәтләнгән вакыйга исә сугыш елларына барып тоташа. 1943 елның сентябрендә 14 яшьлек киномеханик егетләр Кама елгасындагы давылга эләгәләр һәм, үлем белән көрәшеп, исән-сау калалар.

Егетләрнең берсе Зөфәр - өлкән киномеханик, Исрафил Нәбиуллин белән Мидхәт Йосыпов - ярдәмчеләр.

Яр Чаллы кинотеатры директоры Иван Агафонов аларга Алабугадан өч фильмнар алып кайтырга куша. Киномеханиклар Чулман елгасы аша кечкенә генә көймәдә Алабугага юл тоталар. Бару юлы матур була, күктән көзге кояш елмая. Көймә белән идарә итүче Зөфәр үз эшен яхшы башкара, егетләргә дә ишкәк белән ишү серләрен өйрәтеп бара.

Аларга Алабуганың прокат бүлегендә склад мөдирен ике сәгатьләп көтәргә туры килә. Фильмнарны көймәгә төяп, кайтыр юлга чыгалар. Кинәт көчле җил күтәрелә, күк йөзе кап-кара төс ала, болытлар куерганнан-куера, яшене дә озак көттерми. Егетләрнең ишкәгенә каршы зур дулкыннар көймәне төрле яклап йолкый, коеп яңгыр ява башлый. Көймәгә су керә. Егетләр тиз-тиз аны кире бушаталар. Озак та көттерми, төн туа. Әле ярый яшен, әледән-әле яктыртып, көймәчеләргә аргы якны күрсәтеп ала. Егетләрнең берсе, яшеннән куркып, ишкәген суга төшереп җибәрә. Шулвакыт ике кулы белән битен каплаган Мидхәтнең: «Әни, без беттек!» - дигән сүзләре ишетелә. Бер ишкәк белән генә ярга барып җитеп булмаганны Зөфәр яхшы аңлый. Суга сикереп төшә дә колач салып йөзә башлый. Көймәне дә үзеннән калдырмый, бар көченә ярга таба этә.

Елганы озак кичәләр егетләр. Бераздан Зөфәрнең аяклары су төбенә кагылып китә. Ул үз-үзен белештерми: «Җир, җир», - дип кычкырырга көч таба. Мидхәт беренче булып ярга сикереп төшә дә шатлыгыннан: «Әни, без исән, без исән», - дип кабатлый. Әмма өйгә кадәр юл ерак була әле. Җилгә каршы елга ярыннан көймәдә бару мөмкин түгел. Монда да Зөфәрнең зирәклеге булыша. Бурлаклар кебек яр буйлап көймәне тартып кайтырга булалар. Көймәдәге озын чылбыр да эшкә ярап куя. Зөфәр, егетләрнең кәефләрен күтәрергә теләп, җырларга тәкъдим итә. Башта «Интернаңионал»ны җырлыйлар, аннары - «Смело товарищи в ногу» яңгырый. Ниһаять, Үзәк урам башына якынлашалар. Фильмнарны бушаталар, көймәне чыгарып куялар да үзләре Үзәк урам буйлап Иван Григорьевичның өенә күтәреләләр. Иван Григорьевич та төне буе йокламыйча балаларны көткән була...

## Бәхетләрен күпсенмә...

Зөфәр Сәгыйтов нинди эшкә генә алынмасын, аны яхшы билгеләргә генә башкарып чыга. Ә гаилә кору бераз гына икенче планга кала. 36 яшендә ул беренче тапкыр өйләнә. 1978 елда исә үзенең тиңе Людмила ханымны очрата. Яңа гына Түбән Кама музыка техникумын тәмамлап кайткан яшь белгеч белән араларында мәхәббәт хисе кабына. Эшләре дә бергә, гаиләне дә бергә алып баралар, һәм менә инде кырык биш елдан артык алар бер-берсен аңлап гомер итәләр. Балалары, оныклары да Сәгыйтовлар өендә көтеп алынган кунаклар. Бүгенге көндә аның дүрт баласы, тугыз оныгы, бер оныкчыгы бар. Әтиләре янәшәсендәге мөлаем, игътибарлы ханымга да якын итеп, дәү әниебез диеп дәшәләр алар. Шулай булсын, аңлашып яшәүләргә ни җитә?! Гаҗәеп катлаулы да, кызыклы да тормыш юлы үткән Зөфәр абыйның, һәм гомумән, Сәгыйтовлар гаиләсенең бу бәхетле тормышка тулы хакы бар. Күпсенмә, Ходаем!

**Роза ХӘМИДУЛЛИНА,**
**Татарстанның атказанган**
**мәдәният хезмәткәре**